Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлегенең
Аккүл авылы гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 19 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлегенең Аккүл авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Аккүл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Аккүл авылында Колхоз урамы, Комсомол урамы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау;
Аккүл авылына юлларны кардан чистарту (Күпер урамы, Колхоз урамы, Комсомол урамы).

II. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- Аккүл авылының каптированный чишмәсен ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 82 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 48.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар «РИЗА»позициясе өчен бертавыштан тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге составына керүче Аккүл авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Аккүл авылы территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Аккүл авылында Колхоз урамы, Комсомол урамы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау;

Аккүл авылына юлларны кардан чистарту (Күпер урамы, Колхоз урамы, Комсомол урамы).

II. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- Аккүл авылының каптированный чишмәсен ремонтлау;

сораулары буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5, Аккүл авылы, Колхоз урамы, 16Б, Медведка авылы, Дорожная урамы, 32, Михайловка авылы, Центральная урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.П.Бодряева